ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОБУГУЛЬМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КЕЧЕ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ВОСТОЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.10.2019** № **58**

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль
районы Кече Бөгелмә авылы җирлеге Башкарма комитетының
2019 нчы елның 8 нче апрелендәге 21 нче номерлы
«Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең,
реконструкцияләүнең чик параметрларыннан
чыгуга рөхсәт бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентын
раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнар белән тәңгәлләштерү максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кече Бөгелмә авылы җирлеге Башкарма комитетының 2019 нчы елның 8 нче апрелендәге 21 нче номерлы «Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан чыгуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 нче пунктның 5 нче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

- төзүче – үз милке булган җир кишәрлегендә яки башка затның (аңа дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда һәм

килешүләр нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен тапшырганнар яки аңа 2017 нчы елның 29 нче июлендәге 218-ФЗ номерлы «Төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) вакытында өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль законның 13.3 нче статьясы буенча һәм килешүләр нигезендә төзүче үз функцияләрен тапшырган) милке хокукында булган җир кишәрлегендә төзелеш алып баруны, реконструкцияләүне, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү эшләрен алып баруны, инженерлык эзләнүләрен башкаруны, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь төзекләндерү өчен проект документларын әзерләүне тәэмин итүче физик яки юридик зат. Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә үз функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы.

2. Карар текстының калган өлешен үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.М.Юсупов**